ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

# Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү өлкәсендәге программаларны гамәлгә ашыру турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры М.М. Айзатуллинның Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү өлкәсендәге программаларны гамәлгә ашыру турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү өлкәсендәге программаларны гамәлгә ашыру турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, бюджет законнарында каралган очракларда, Татарстан Республикасы бюджетына керә торган өстәмә керемнәрне өстенлекле тәртиптә Татарстан Республикасы шәһәр һәм авыл җирлекләренең коммуналь һәм инженерлык инфраструктурасын модернизацияләү чараларына җибәрүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Су белән тәэмин итүне, су чыгаруны һәм агым суларны чистартуны гамәлгә ашыручы коммуналь комплекс оешмаларының күрсәтелгән өлкәгә инвестицияләр җәлеп итү максатында инвестиция җәлеп итүчәнлеген арттыру эшен дәвам итәргә.

3.2. Торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү өлкәсендәге программаларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән федераль акчаларның тулаем һәм нәтиҗәле үзләштерелүен тәэмин итәргә.

3.3. «Безнең ишегалды» республика программасын гамәлгә ашыру кысаларында, инженерлык коммуникацияләрен алмаштыру программалары белән бергә эшләүне тәэмин итеп, эшләрне үз вакытында башкару һәм аларның сыйфатын тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

3.4. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны (алга таба – күпфатирлы йортларга капиталь ремонт) үз вакытында уздыруны, шулай ук күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау кысаларында уздырылган эшләр буенча гарантия йөкләмәләре срогын үтәүне тикшереп торуны көчәйтергә.

3.5. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү, күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау һәм территорияләрне төзекләндерү мәсьәләләре буенча халыкка мәгълүмат җиткерү эшен көчәйтергә.

3.6. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан ишегалды территорияләрен төзекләндерү барышына халыкны җәлеп итүне мониторинглауны дәвам итәргә.

4. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планы чараларын үтәү барышы турында, шулай ук капиталь ремонт фондын булдыруның нәтиҗәле рәвешләре хакында халыкка мәгълүмат җиткерүдә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына ярдәм күрсәтергә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетына Татарстан Республикасында республика башкарма хакимиятенең тармак органнары һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү өлкәсендәге законнарны мониторинглау эшен дәвам итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 29 октябре
№ 452-VII ДС